**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О Конституционном совете Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
8 июня 2023 года

## Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон определяет статус, полномочия, основы организации и цели деятельности, состав и порядок образования Конституционного совета Республики Татарстан, а также статус членов Конституционного совета Республики Татарстан.

## Статья 2. **Статус Конституционного совета Республики Татарстан**

1. Конституционный совет Республики Татарстан (далее – Конституционный совет) создается на основании Федерального конституционного закона от 8 декабря 2020 года № 7-ФКЗ «О внесении изменений в отдельные федеральные конституционные законы» и Конституции Республики Татарстан, является постоянно действующим государственным органом Республики Татарстан, осуществляющим свою деятельность в целях укрепления конституционной законности в Республике Татарстан.
2. Порядок деятельности Конституционного совета, в том числе сроки принятия актов Конституционного совета, устанавливается Регламентом Конституционного совета Республики Татарстан (далее – Регламент Конституционного совета) в соответствии с федеральными законами, настоящим Законом и иными законами Республики Татарстан. Основной формой деятельности Конституционного совета являются заседания, на которых решаются вопросы, отнесенные к его полномочиям.
3. Конституционный совет является юридическим лицом, имеет печать и бланки с изображением Государственного герба Республики Татарстан и своим наименованием.

Статья 3. **Правовая основа деятельности Конституционного совета**

Конституционный совет осуществляет свою деятельность на основе Конституции Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан, федеральных конституционных законов, федеральных законов и иных нормативных правовых актов Российской Федерации, настоящего Закона, иных законов и нормативных правовых актов Республики Татарстан.

Статья 4. **Принципы деятельности Конституционного совета**

Деятельность Конституционного совета основывается на принципах законности, объективности, организационной самостоятельности, функциональной независимости, коллегиальности, открытости и гласности.

Статья 5. **Полномочия Конституционного совета**

1. Конституционный совет по запросам Главы (Раиса) Республики Татарстан, Государственного Совета Республики Татарстан, его Президиума и комитетов, депутатов Государственного Совета Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан, Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан, Уполномоченного по правам ребенка в Республике Татарстан, Уполномоченного при Главе (Раисе) Республики Татарстан по защите прав предпринимателей, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан выносит заключения о конституционности или неконституционности:

1) законов Республики Татарстан или их отдельных положений;

2) нормативных правовых актов Главы (Раиса) Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан, иных органов исполнительной власти Республики Татарстан;

3) нормативных правовых актов органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан.

2. Конституционный совет выносит заключения о конституционности или неконституционности законов Республики Татарстан или их отдельных положений, нормативных правовых актов Главы (Раиса) Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан, иных органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан по обращениям граждан и организаций, полагающих, что их права нарушены указанными нормативными правовыми актами.

3. Конституционный совет выносит заключения по проектам законов Республики Татарстан о принятии Конституции Республики Татарстан, внесении изменений и дополнений в Конституцию Республики Татарстан, внесенным в Государственный Совет Республики Татарстан (далее – проект закона Республики Татарстан).

4. Конституционный совет по запросам Главы (Раиса) Республики Татарстан, Государственного Совета Республики Татарстан, его Президиума и комитетов, депутатов Государственного Совета Республики Татарстан, Кабинета Министров Республики Татарстан, Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан, Уполномоченного по правам ребенка в Республике Татарстан, Уполномоченного при Главе (Раисе) Республики Татарстан по защите прав предпринимателей, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, граждан и организаций разъясняет положения Конституции Республики Татарстан.

5. Конституционный совет по запросу Главы (Раиса) Республики Татарстан выражает мнение о соответствии Конституции Республики Татарстан проектов договоров (соглашений), заключаемых от имени Республики Татарстан с субъектами Российской Федерации (далее – проект договора Республики Татарстан).

6. Конституционный совет в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан взаимодействует с государственными органами Республики Татарстан, органами местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, а также с общественными объединениями и иными организациями.

7. Конституционный совет осуществляет научно-методическое обеспечение развития конституционного законодательства Республики Татарстан.

8. Конституционный совет содействует правовому просвещению, формированию и развитию правовой культуры населения Республики Татарстан.

9. Конституционный совет рассматривает обращения граждан в порядке, установленном федеральным законом.

10. Конституционный совет утверждает Регламент Конституционного совета, положение об аппарате Конституционного совета Республики Татарстан.

Статья 6. **Состав и порядок образования Конституционного совета**

1. Конституционный совет состоит из трех членов Конституционного совета, включая Председателя Конституционного совета.

2. Члены Конституционного совета назначаются на должность Государственным Советом Республики Татарстан большинством голосов от установленного числа депутатов Государственного Совета Республики Татарстан.

3. Одного кандидата в члены Конституционного совета представляет Государственному Совету Республики Татарстан Глава (Раис) Республики Татарстан, двух кандидатов – Председатель Государственного Совета Республики Татарстан.

4. Назначение на должность члена Конституционного совета осуществляется в индивидуальном порядке и оформляется постановлением Государственного Совета Республики Татарстан.

5. Председатель Конституционного совета назначается на должность Государственным Советом Республики Татарстан по предложению Главы (Раиса)

Республики Татарстан из числа назначенных Государственным Советом Республики Татарстан членов Конституционного Совета.

6. Конституционный совет вправе осуществлять свою деятельность при наличии в его составе не менее двух членов Конституционного совета.

7. В случае прекращения полномочий члена Конституционного совета представление о назначении другого лица на вакантное место вносится в Государственный Совет Республики Татарстан соответственно Главой (Раисом) Республики Татарстан и Председателем Государственного Совета Республики Татарстан в порядке, установленном настоящей статьей.

Статья 7. **Требования, предъявляемые к кандидату в члены Конституционного совета**

Членом Конституционного совета может быть гражданин Российской Федерации не моложе 35 лет, имеющий высшее юридическое образование по специальности «Юриспруденция» или высшее образование по направлению подготовки «Юриспруденция» квалификации (степени) «магистр» при наличии диплома бакалавра по направлению подготовки «Юриспруденция», стаж работы в области юриспруденции не менее 10 лет, а также не имеющий или не имевший судимости либо уголовное преследование в отношении которого прекращено по реабилитирующим основаниям.

Статья 8. **Статус члена Конституционного совета**

1. Члены Конституционного совета замещают государственные должности Республики Татарстан и осуществляют свои полномочия на профессиональной постоянной основе.

2. Член Конституционного совета обязан прекратить несовместимую с его статусом деятельность в течение 14 календарных дней со дня назначения на должность.

3. Члены Конституционного совета назначаются на должность сроком на пять лет. Одно и то же лицо не может быть назначено членом Конституционного совета более двух сроков.

4. На членов Конституционного совета распространяются ограничения, запреты и обязанности, связанные с замещением государственных должностей Республики Татарстан, установленные законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 9. **Председатель Конституционного совета**

1. Председатель Конституционного совета:

1) руководит подготовкой заседаний Конституционного совета, созывает их и председательствует на них;

2) вносит на обсуждение Конституционного совета вопросы, подлежащие рассмотрению на его заседаниях;

3) представляет Конституционный совет в отношениях с государственными органами, органами местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, общественными объединениями, организациями;

4) осуществляет общее руководство аппаратом Конституционного совета;

5) осуществляет иные полномочия в соответствии с настоящим Законом и Регламентом Конституционного совета.

2. Порядок временного исполнения полномочий Председателя Конституционного совета в случаях, когда он не в состоянии исполнять свои обязанности, устанавливается Регламентом Конституционного совета.

Статья 10. **Прекращение полномочий члена Конституционного совета**

1. Полномочия члена Конституционного совета прекращаются по основаниям, предусмотренным для прекращения полномочий лиц, замещающих государственные должности Республики Татарстан.

2. Прекращение полномочий члена Конституционного совета осуществляется по решению Государственного Совета Республики Татарстан.

3. Представление о досрочном прекращении полномочий Председателя Конституционного совета вносится в Государственный Совет Республики Татарстан Председателем Государственного Совета Республики Татарстан. Представления о досрочном прекращении полномочий иных членов Конституционного совета вносятся в Государственный Совет Республики Татарстан Председателем Конституционного совета.

Статья 11. **Акты Конституционного совета**

1. Конституционный совет по вопросам, перечисленным в частях 1–3 и 5 статьи 5 настоящего Закона, принимает заключения, а по вопросу, указанному в части 4 статьи 5 настоящего Закона, – разъяснения.

2. Заключения Конституционного совета должны основываться на материалах, исследованных Конституционным советом. При вынесении заключения Конституционный совет оценивает буквальный смысл рассматриваемого нормативного правового акта, проекта закона Республики Татарстан, проекта договора Республики Татарстан. При рассмотрении нормативного правового акта Конституционный совет также оценивает смысл, придаваемый ему официальным и иным разъяснением или сложившейся правоприменительной практикой. Конституционный совет выносит заключение только по предмету, указанному в обращении, а при рассмотрении нормативного правового акта – лишь в отношении той его части, конституционность которой подвергается сомнению в обращении. Конституционный совет при вынесении заключения не связан основаниями и доводами, изложенными в обращении.

3. В заключении Конституционный совет излагает суждение о соответствии или несоответствии нормативного правового акта Республики Татарстан, нормативного правового акта органа местного самоуправления муниципального образования Республики Татарстан либо отдельных их положений, проекта закона

Республики Татарстан, проекта договора Республики Татарстан Конституции Республики Татарстан.

4. Заключение, разъяснение принимаются Конституционным советом по результатам открытого голосования. Заключение, разъяснение Конституционного совета считаются принятыми при условии, что за них проголосовало не менее двух членов Конституционного совета. В случае досрочного прекращения полномочий одного из членов Конституционного совета или временного его отсутствия в связи с состоянием здоровья или другими обстоятельствами, временно препятствующими осуществлению полномочий, если при принятии заключения, разъяснения голоса членов Конституционного совета разделились поровну, голос Председателя Конституционного совета или временно исполняющего обязанности Председателя Конституционного совета является решающим.

5. Заключение Конституционного совета не позднее 10 дней со дня его вынесения направляется в государственные органы Республики Татарстан, органы местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, должностным лицам, которых касается заключение Конституционного совета.

6. Заключение Конституционного совета, вынесенное по вопросам, перечисленным в частях 1 и 2 статьи 5 настоящего Закона, разъяснение Конституционного совета подлежат опубликованию в газетах «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан», на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU), а также на официальном сайте Конституционного совета в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

7. Заключение Конституционного совета, которым нормативный правовой акт Республики Татарстан, нормативный правовой акт органа местного самоуправления муниципального образования Республики Татарстан либо отдельные их положения признаны не соответствующими Конституции Республики Татарстан либо из которого вытекает необходимость устранения пробела в правовом регулировании, подлежит обязательному рассмотрению органом (должностным лицом), издавшим этот нормативный правовой акт, не позднее трех месяцев после опубликования заключения Конституционного совета.

### Статья 12. **Доклад о состоянии конституционной законности в Республике Татарстан**

Конституционный совет один раз в год направляет доклад о состоянии конституционной законности в Республике Татарстан Главе (Раису) Республики Татарстан и в Государственный Совет Республики Татарстан. Доклад представляется на заседании Государственного Совета Республики Татарстан Председателем Конституционного совета.

### Статья 13. **Аппарат Конституционного совета**

1. Деятельность Конституционного совета обеспечивается аппаратом Конституционного совета.

2. Конституционный совет в пределах своей сметы расходов устанавливает структуру и штатное расписание аппарата Конституционного совета.

3. Работники аппарата Конституционного совета являются государственными гражданскими служащими Республики Татарстан.

4. В целях технического обеспечения деятельности Конституционного совета в штатное расписание аппарата Конституционного совета могут включаться должности, не отнесенные к должностям государственной гражданской службы Республики Татарстан.

Статья 14. **Финансовое обеспечение деятельности Конституционного совета**

1. Финансовое обеспечение деятельности Конституционного совета осуществляется за счет средств бюджета Республики Татарстан.

2. Финансирование Конституционного совета предусматривается отдельной строкой в законе о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год и плановый период.

Статья 15. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
13 июня 2023 года
№ 44-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Конституция советы турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 8 июнендә
кабул ителде

## 1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Конституция советының статусын, вәкаләтләрен, аны оештыру нигезләрен һәм эшчәнлеге максатларын, составын һәм аны оештыру тәртибен, шулай ук Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзаларының статусын билгели.

## 2 статья. **Татарстан Республикасы Конституция советы статусы**

1. Татарстан Республикасы Конституция советы (алга таба – Конституция советы) «Аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 декабрендәге 7-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә төзелә һәм үз эшчәнлеген Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкны ныгыту максатларында гамәлгә ашыра торган даими эшләүче Татарстан Республикасы дәүләт органы булып тора.

2. Конституция советының эшчәнлек тәртибе, шул исәптән Конституция советы актларын кабул итү сроклары, федераль законнар, әлеге Закон һәм башка Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Конституция советы Регламенты (алга таба – Конституция советы Регламенты) белән билгеләнә. Конституция советы эшчәнлегенең төп рәвеше утырышлардан гыйбарәт, аларда аның вәкаләтләренә кергән мәсьәләләр хәл ителә.

3. Конституция советы юридик зат булып тора, Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән һәм үз исеме төшерелгән мөһергә һәм бланкларга ия була.

## 3 статья. **Конституция советы эшчәнлегенең хокукый нигезе**

Конституция советы үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль конституциячел законнар,

федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон, бүтән Татарстан Республикасы законнары һәм норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

4 статья. **Конституция советының эшчәнлек принциплары**

Конституция советы эшчәнлеге законлылык, объективлык, оештыру мөстәкыйльлеге, функциональ бәйсезлек, коллегиальлек, ачыклык һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнә.

5 статья. **Конституция советы вәкаләтләре**

1. Конституция советы Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның Президиумы һәм комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары мөрәҗәгате буенча түбәндәгеләрнең конституциячеллеге яисә конституциячел булмавы турында бәяләмәләр чыгара:

1) Татарстан Республикасы законнарының яисә аларның аерым нигезләмәләренең;

2) Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, башка Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларының;

3) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының.

2. Конституция советы Татарстан Республикасы законнары яисә аларның аерым нигезләмәләре, Татарстан Республикасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, башка Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән үз хокуклары бозылган дип санаучы гражданнарның һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләре буенча әлеге норматив хокукый актларның конституциячеллеге яисә конституциячел булмавы турында бәяләмәләр чыгара.

3. Конституция советы Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү, Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелгән законнар проектлары (алга таба – Татарстан Республикасы законы проекты) буенча бәяләмәләр чыгара.

4. Конституция советы Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның Президиумы һәм комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан

Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләренә аңлатма бирә.

5. Конституция советы Татарстан Республикасы Рәисе мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы исеменнән Россия Федерациясе субъектлары белән төзелә торган шартнамәләр (килешүләр) проектларының (алга таба – Татарстан Республикасы шартнамәсе проекты) Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүе турында үз фикерен белдерә.

6. Конституция советы Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

7. Конституция советы Татарстан Республикасы конституциячел законлылык үсешен фәнни-методик тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

8. Конституция советы Татарстан Республикасы халкын хокукый агартуга, анда хокукый культураны булдыруга һәм үстерүгә ярдәм итә.

9. Конституция советы гражданнар мөрәҗәгатьләрен федераль законда билгеләнгән тәртиптә карый.

10. Конституция советы Конституция советы Регламентын, Татарстан Республикасы Конституция советы аппараты турында нигезләмәне раслый.

6 статья. **Конституция советы составы һәм аны төзү тәртибе**

1. Конституция советы, Конституция советы Рәисен дә кертеп, өч Конституция советы әгъзасыннан тора.

2. Конституция советы әгъзалары вазыйфага Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән билгеләп куела.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Конституция советы әгъзаларына бер кандидатны Татарстан Республикасы Рәисе, ике кандидатны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тәкъдим итә.

4. Конституция советы әгъзасын вазыйфага билгеләп кую индивидуаль тәртиптә гамәлгә ашырыла һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән рәсмиләштерелә.

5. Конституция советы Рәисе вазыйфага Татарстан Республикасы Дәүләт Советы билгеләп куйган Конституция советы әгъзалары арасыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдиме белән билгеләп куела.

6. Конституция советы, составында кимендә ике Конституция советы әгъзасы булганда, үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга хокуклы.

7. Конституция советы әгъзасы вәкаләтләре туктатылган очракта вакантлы урынга башка затны билгеләп кую турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә тиешенчә Татарстан

Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан кертелә.

7 статья. **Конституция советы әгъзасына кандидатка карата куела торган таләпләр**

«Юриспруденция» белгечлеге буенча югары юридик белеме яисә «Юриспруденция» әзерлек юнәлеше буенча бакалавр дипломы булганда «магистр» квалификацияле (дәрәҗәле) «Юриспруденция» әзерлек юнәлеше буенча югары белеме булган, юриспруденция өлкәсендә кимендә 10 ел эш стажы булган, хөкем ителүе булмаган яисә хөкем ителмәгән йә аңа карата җинаять эзәрлекләве реабилитация нигезендә туктатылган, 35 яшьтән яшьрәк булмаган Россия Федерациясе гражданы Конституция советы әгъзасы була ала.

8 статья. **Конституция советы әгъзасы статусы**

1. Конституция советы әгъзалары Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын били һәм үз вәкаләтләрен профессиональ даими нигездә башкара.
2. Конституция советы әгъзасы үз статусына туры килми торган эшчәнлекне вазыйфага билгеләнеп куелган көннән башлап 14 календарь көн эчендә туктатырга тиеш.
3. Конституция советы әгъзалары вазыйфага биш елга билгеләнеп куела. Бер үк зат Конституция советы әгъзасы итеп ике сроктан артыкка билгеләнеп куела алмый.
4. Конституция советы әгъзаларына Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүгә бәйле Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән чикләүләр, тыюлар һәм бурычлар тарала.

9 статья. **Конституция советы Рәисе**

1. Конституция советы Рәисе:
1) Конституция советы утырышларын әзерләүгә җитәкчелек итә, аларны чакыра һәм аларга рәислек итә;
2) Конституция советына аның утырышларында каралырга тиешле мәсьәләләрне фикер алышуга кертә;
3) дәүләт органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар белән үзара эшчәнлектә Конституция советын тәкъдим итә;
4) Конституция советы аппаратына гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра;
5) әлеге Закон һәм Конституция советы Регламенты нигезендә башка вәкаләтләрне башкара.
2. Конституция советы Рәисе үз вәкаләтләрен башкара алмаган очракта аның вәкаләтләрен вакытлыча башкару тәртибе Конституция советы Регламенты белән билгеләнә.

10 статья. **Конституция советы әгъзасы вәкаләтләрен туктату**

1. Конституция советы әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вәкаләтләрен туктату өчен каралган нигезләр буенча туктатыла.

2. Конституция советы әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән туктатыла.

3. Конституция советы Рәисе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан кертелә. Конституция советының башка әгъзалары вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Конституция советы Рәисе тарафыннан кертелә.

11 статья. **Конституция советы актлары**

1. Конституция советы әлеге Законның 5 статьясындагы 1 – 3 һәм 5 өлешләрендә саналган мәсьәләләр буенча бәяләмәләр, ә әлеге Законның 5 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән мәсьәлә буенча аңлатмалар кабул итә.

2. Конституция советы бәяләмәләре Конституция советы тарафыннан тикшерелгән материалларга нигезләнгән булырга тиеш. Бәяләмә чыгарганда Конституция советы карала торган норматив хокукый актның, Татарстан Республикасы законы проектының, Татарстан Республикасы шартнамәсе проектының турыдан-туры мәгънәсен бәяли. Норматив хокукый актны караганда Конституция советы аңа рәсми һәм башка аңлатмада яисә гамәлдәге хокук куллану тәҗрибәсендә бирелә торган мәгънәне дә бәяли. Конституция советы бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән мәсьәлә буенча гына, ә норматив хокукый актны караганда аның мөрәҗәгатьтә конституциячеллегенә шик белдерелгән өлешенә карата гына бәяләмә чыгара. Бәяләмә чыгарганда Конституция советы мөрәҗәгатьтә бәян ителгән нигезләүләргә һәм дәлилләүләргә бәйле түгел.

3. Конституция советы бәяләмәдә Татарстан Республикасы норматив хокукый актының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы норматив хокукый актының яки аларның аерым нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы законы проектының, Татарстан Республикасы шартнамәсе проектының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүе яисә туры килмәве турында фикерләрен бәян итә.

4. Бәяләмә, аңлатма Конституция советы тарафыннан ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча кабул ителә. Конституция советының кимендә ике әгъзасы яклап тавыш биргән очракта Конституция советы бәяләмәсе, аңлатмасы кабул ителгән дип санала. Конституция советы әгъзаларының берәрсенең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яисә ул сәламәтлегенә яки вәкаләтләрне башкаруга вакытлыча комачаулык итә торган башка хәлләргә бәйле рәвештә вакытлыча булмаган очракта, бәяләмә, аңлатма кабул иткәндә Конституция советы әгъзалары

тавышы тигез бүленсә, Конституция советы Рәисе яисә Конституция советы Рәисе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы тавышы хәлиткеч була.

5. Конституция советы бәяләмәсе чыгарылган көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча Конституция советы бәяләмәсе кагыла торган Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына, вазыйфаи затларга җибәрелә.

6. Әлеге Законның 5 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә саналган мәсьәләләр буенча чыгарылган Конституция советы бәяләмәсе, Конституция советы аңлатмасы «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында басылып чыгарга, «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), шулай ук Конституция советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

7. Татарстан Республикасы норматив хокукый актын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы норматив хокукый актын йә аларның аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип таныган яки хокукый җайга салудагы өзеклекне юкка чыгару таләбе булган Конституция советы бәяләмәсе әлеге норматив хокукый актны чыгарган орган (вазыйфаи зат) тарафыннан Конституция советы бәяләмәсе басылып чыкканнан соң өч айдан да соңга калмыйча мәҗбүри каралырга тиеш.

12 статья. **Татарстан Республикасында конституциячел законлылык торышы турында доклад**

Конституция советы Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына елга бер тапкыр Татарстан Республикасында конституциячел законлылык торышы турында доклад юллый. Доклад Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Конституция советы Рәисе тарафыннан тәкъдим ителә.

13 статья. **Конституция советы аппараты**

1. Конституция советы эшчәнлеген Конституция советы аппараты тәэмин итә.

2. Конституция советы үзенең чыгымнар сметасы кысаларында Конституция советы аппараты структурасын һәм штат расписаниесен билгели.

3. Конституция советы аппараты хезмәткәрләре Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре булып тора.

4. Конституция советы эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү максатларында Конституция советы аппараты штат расписаниесенә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына кертелмәгән вазыйфалар өстәлергә мөмкин.

14 статья. **Конституция советы эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү**

1. Конституция советы эшчәнлеге финанс белән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тәэмин ителә.

2. Конституция советын финанслау чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында законда аерым статья белән карала.

15 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 13 июнь
№ 44-ТРЗ